Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе
конкурс процедураларын үткәрмичә генә дәүләт граждан
хезмәте вазыйфасына конкурс
ИГЪЛАН ИТӘ

**<u>Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм эшчәнлек башкару бүлегенең 1 разрядлы белгече</u>**

***<u>Претендентларга төп таләпләр:</u>***

- урта һөнәри белем булу (һөнәри белем бирү юнәлешенә таләпләр, шулай ук. дәүләт граждан хезмәте стажы һәм белгечлек буенча эш тәҗрибәсенә карата таләпләр куелмый);

- компьютерда, шул исәптән интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, мәгълүмат базалары, электрон почта, текст рекдакторында, электрон таблицалар белән эшли белү; электрон документлардагы график объектлар белән эш итә белү;
- эшчәнлек алып бару һәм рәсми хат әзерләү нигезләрен белү.

***<u>1 разрядлы белгечнең төп бурычлары:</u>***

- ТКХ ДМС, «Халык контроле», ССТУ (турыдан-туры эш урынында укыту һәм стажировка) дәүләт мәгълүмат системаларында модератор (мониторинг) функцияләрен гамәлгә ашыру;

- документлар белән эшләү (теркәү, контрольдә тоту).

***<u>Эш вакыты:</u>***

Биш көнлек эш атнасы:
Дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр,
төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.
Җомга: 8.30 сәгатьтән 16.15 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.
Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

***<u>Хезмәт хакы:</u>***

Сынау срогына 14 000 сум хезмәт хакы каралган.

Сынау срогыннан соң хезмәт хакы 14 000 меңнән алып 15 000 мең сумга кадәр булырга мөмкин (класс чины бирелүне, дәүләт граждан хезмәте стажын исәпкә алып). Уртача еллык хезмәт хакы 25000.

***<u>Гарантияләр:</u>***

1. Тулы социаль пакет (Пенсия фондына, социаль иминият фондына, медицина иминияте фондына салымнар күчерү);
2. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен ел саен диспансеризацияләү;

3. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең гомерен ел саен иминиятләштерү;
4. Хезмәткә сәләтсезлек кәгазьләре түләнә;
5. Ел саен отпуск (30 календарь көне), эшләгән еллар өчен отпуск, уку өчен кирәкле отпуск (сессия), йөклелек һәм бала тудыру һәм 3 яшенә җиткәнчегә бала карау буенча отпуск бирелә.
6. Татарстан Республикасы бюджеты хисабына дәүләт граждан хезмәткәрләренең квалификациясен өч елга бер тапкыр күтәрү;
7. Карьера үсеше (вакантлы вазыйфаларны биләү буенча конкурс процедураларында катнашу яки югарыдагы вазыйфага кадрлар резервы);
8. 16 яшькә кадәрге балалары булган аналарга айга 1 мәртәбә эш буш вакыт бирелә;
9. Социаль ипотека буенча фатир алу мөмкинлеге (теркәлү буенча үз администрациядә чиратка басу).

***<u>Эшкә алганда кирәкле документлар исемлеге:</u>***

Теләк белдергән гражданин түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыра:

1) шәхси гариза;
2) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фоторәсемнәр (өч фото 2,5 х 3,0 һәм ике фото 4х6 – төсле, почмагы булмаган, ак фонлы, ялтыравыклы булмаган кәгазьдә);
3) паспорт күчермәсе (фото, прописка, 19 бит) яки аны алмаштыра торган документ күчермәсе;
4) мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе;
5) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе (ИНН);
6) хәрби исәпкә алу документлары – хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;
7) медицина полисы күчермәсе;
8) гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга комачаулык итүче авыруларның булмавы турында документ (№001-ДС/у формасы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга комачаулаучы авыру булуы (булмавы) турында медицина учреждениесе бәяләмәсе»);
9) кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслый торган документлар:
а. хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;
б. һөнәри белем, өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелүе турында документлар күчермәләре.
Нотариаль яки кадр хезмәтләре тарафыннан эш (хезмәт итү) урыны буенча таныкланган документларның күчермәләре;
10) керемнәр турында, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр;
11) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (3 данә);

12) типлаштырылган йөкләмә;
13) автобиография.

Документлар Казан шәһәре, Б.Красная урамы, 15/9 адресы буенча кабул ителә. Элемтә өчен телефон(факс): (843) 236-93-66.